**Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы**
**Иске Кармәт авыл җирлеге башлыгы**

**Карар**

**№ 4** **«17» октябрь 2022 ел**

«Аксубай муниципаль районы
Иске Кармәт авыл җирлегенең
Иске Кармәт авылында халык
җыены үткәрү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Аксубай муниципаль районы «Иске Кармәт авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 ст. нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. ТР, Аксубай муниципаль районы, Иске Кармәт авылы, Ленин урамы, 37 нче йорт адресы буенча урнашкан клуб бинасында 2022 елның 27 октябрендә сәгать 14:00 минутта Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Иске Кармәт авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены уздырырга.

2. "2023 елда һәр балигъ булган һәм Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлеге Иске Кармәт торак пунктының территориясендә теркәлгән кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә (1 төркем инвалид, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан тыш) һәм алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә килешәсезме?:

I. **Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:**
- вак таш сатып алу;
- кышкы чорда юлларны карап тоту (кышкы чорда юлларны кардан чистарту өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу).

**II. Территорияне төзекләндерү:**
- трактор өчен асылмалы җиһазлар алу;
- урам утларын оештыруны тәэмин итү өчен урам утлары сатып алу.

**III. Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу, халыкны ягулык белән тәэмин итү Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә оештыру**
- тирән насос сатып алу.

“ӘЙЕ” “ЮК”

3. Әлеге карарны Иске Кармәт авыл җирлегенең «Интернет» мәгълүмат–телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырылган рәсми сайтында: http://aksubaevo.tatar.ru, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Иске Кармәт авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru/ игълан итәргә.

Иске Кармәт авыл җирлеге башлыгы: А.В.Парфенов